**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«27» 09 2021 ел** **№ 209**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 04 маендагы 94 нче номерлы «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче Азнакай муниципаль районы физкультура спорт учреждениеләренең яшь белгечләренә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 03 июлендәге 537 нче номерлы «Гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган яшь белгечләргә, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» карарын үтәү йөзеннән, карар итә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 04 маендагы 94 нче номерлы «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче Азнакай муниципаль районы физкультура спорт учреждениеләренең яшь белгечләренә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктта «30 яшькә кадәр,» сүзләрен «35 яшькә кадәр»сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 10 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

"Хезмәткәр - яшь белгечләргә хуҗалык эшләре өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү, саклау, туктату турында карар учреждение боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Хезмәткәрләр - яшь белгечләрне хуҗалык белән тәэмин итүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алу хокукы, чакырылыш буенча хәрби хезмәттән яки альтернатив граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң өч айдан да соңга калмыйча эшкә урнашу шарты белән, Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт иткән яки альтернатив граждан хезмәте вакытында саклана.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 3 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru//.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов